| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 21 апрель № 236

г. Казань

«Профессор А.Ф.Агафонов исемендәге республика клиник инфекция хастаханәсе» һәм Казан шәһәренең «Инфекцияле авыруларның лаборатория диагностикасы буенча шәһәр диагностика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениеләрен Казан шәһәренең «Инфекцияле авыруларның лаборатория диагностикасы буенча шәһәр диагностика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесен «Профессор А.Ф.Агафонов исемендәге республика клиник инфекция хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә кушу рәвешендә үзгәртеп төзү турында

Татарстан Республикасында дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләре белән идарә итүне оптимальләштерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Казан шәһәре, Җиңү Проспекты урамы, 83 йорт адресы буенча урнашкан «Профессор А.Ф.Агафонов исемендәге республика клиник инфекция хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесен (алга таба – Профессор А.Ф.Агафонов исемендәге республика клиник инфекция хастаханәсе) һәм Казан шәһәре, Н.Ершов урамы, 54 йорт адресы буенча урнашкан Казан шәһәренең «Инфекцияле авыруларның лаборатория диагностикасы буенча шәһәр диагностика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесен (алга таба – Инфекцияле авыруларның лаборатория диагностикасы буенча шәһәр диагностика үзәге) Инфекцияле авыруларның лаборатория диагностикасы буенча шәһәр диагностика үзәген Профессор А.Ф.Агафонов исемендәге республика клиник инфекция хастаханәсенә кушу рәвешендә, Профессор А.Ф.Агафонов исемендәге республика клиник инфекция хастаханәсе эшчәнлегенең төп максатларын саклап, үзгәртеп төзү турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. Профессор А.Ф.Агафонов исемендәге республика клиник инфекция хастаханәсенең пландагы йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итү, шулай ук Профессор А.Ф.Агафонов исемендәге республика клиник инфекция хастаханәсен үзгәртеп төзү буенча чараларны финанслау Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы раслый торган тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасында каралган акча кысаларында гамәлгә ашырыла.

3. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына:

Профессор А.Ф.Агафонов исемендәге республика клиник инфекция хастаханәсен гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкарырга;

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән учреждениеләрне үзгәртеп төзү белән бәйле законда каралган чараларны үткәрүне тәэмин итәргә;

үзгәртеп төзү чаралары нәтиҗәсендә эштән чыгарыла торган хезмәткәрләргә законнар нигезендә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне тәэмин итәргә;

Профессор А.Ф.Агафонов исемендәге республика клиник инфекция хастаханәсе Уставында каралган төп эшчәнлеге нигезендә аның өчен ел саен дәүләт йөкләмәсен расларга;

Уставка тиешле үзгәрешләрне керткән һәм автоном учреждениенең Күзәтү советын раслаганнан соң 10 көн эчендә автоном учреждение тарафыннан Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына оператив идарә итү хокукында дәүләт мөлкәтен беркетү өчен кирәкле документларны, шул исәптән күчемсез милек объектларына техник документларны тапшыруны тәэмин итәргә.

4. Профессор А.Ф.Агафонов исемендәге республика клиник инфекция хастаханәсе Уставына кертелгән үзгәрешләрне дәүләт теркәвенә алган көннән соң 90 көн эчендә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына элек даими (вакыты чикләнмәгән) куллану хокукында Инфекцияле авыруларның лаборатория диагностикасы буенча шәһәр диагностика үзәгенеке булган җир кишәрлекләрен даими (вакыты чикләнмәгән) куллану хокукында Профессор А.Ф.Агафонов исемендәге республика клиник инфекция хастаханәсенә тапшырырга.

5. Профессор А.Ф.Агафонов исемендәге республика клиник инфекция хастаханәсе Уставына кертелгән үзгәрешләрне дәүләт теркәвенә алган көннән соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына элек оператив идарә итү хокукында Инфекцияле авыруларның лаборатория диагностикасы буенча шәһәр диагностика үзәгенә беркетелгән булган, шул исәптән аеруча кыйммәтле дәүләт мөлкәтен учреждениегә беркетергә.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\236.docx